СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 3-29 — 15 нче ноябрь 2023ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге "Физик затлар милкенә салым турында" 1-2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Мамадыш районы прокуратурасынын 2023 елның 13 октябрендәге 02-08-02-2023 номерлы протесты, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге "Физик затлар милкенә салым турында" 1-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Караның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:
2.1. Түбәндәгеләргә карата 0,1 % күләмендә:
- гаражлар һәм машина урыннары шул исәптән әлеге пунктның 2.4 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнар;
- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелмәләр;
2.2. 0,2 % күләмендә түбәндәгеләргә карата:
-фатирлар, фатирларның өлешләре ;
-бүлмәләр;
2.3. 0,3 % күләмендә түбәндәгеләргә карата:
-торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- әгәр мондый объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса, төзелеп бетмәгән объектлар;
- составына кимендә бер генә торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;
2.4. 2 % әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;
2.5. 0,5 % салым салуның башка объектларына карата.».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Урта Кирмән
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе Б.Ф.Хасанов